БОЗЛЫ БӘЛА
Белгечләр аяк астына карап йөрергә киңәш итә
> 3

УЕНЧЫК ТҮГЕЛ
Интернетта акча эшләүнең яңа төре чәчәк ата
> 4

КӨЧЛЕ РУХЛЫЛАР
Йөргәндә уңайсызлык сизсә дә, тормыш юлында тигез атлый ул
> 4

БИЛАЛЕТДИНОВ КАЙТТЫ
Легендар остаз «Ак барс»та тынычлык урнаштырачак
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 180 (28953) | Сишәмбе | 6 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

МИРАС ТИРӘСЕНДӘ БЕРЛӘШҮ

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНА 56 ИЛДӘН ҖЫЕЛГАН БЕЛГЕЧЛӘР ТАРИХНЫҢ КИЛӘЧӘК ӨЧЕН ӘҺӘМИЯТЕ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШӘ

Казанда Бөтендөнья табигый һәм мәдәни мирасны саклау конвенциясенең 50 еллыгына багышланган халыкара форум башланды. Дөньяның 56 иленнән килгән 1000нән артык белгеч берничә көн дәвамында, сәяси каршылыкларны онытып торып, мәдәни һәм табигый мирас турында сөйләшәчәк.

vk.com

Сөйләшик һәм аңлашыйк

Форумда катнашучыларны иң беренче булып Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сәламләде. Аның фикеренчә, ЮНЕСКО билгеләгән кыйммәтләр бөтен кешелек дөньясы өчен иң мөһимнәрдән санала.

– Сезне гомер-гомергә Көнбатыш һәм Көнчыгышны тоташтыручы урын булган Татарстанда сәламләвемә чиксез шатмын. Дөньядагы катлаулы хәлләргә карамастан, республикабызга килергә вакыт һәм мөмкинлек табуыгыз куандыра, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Быел без Мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенциянең 50 еллыгын билгеләп узабыз. Әлеге документ дөньякүләм мирасны саклап калу һәм популярлаштыру өлкәсендә халыкара законнарның нигезе булып тора. 50 ел эчендә дөньядагы 1154 объект ЮНЕСКО исемлегенә кертелде. Россия, шул исәптән Татарстан да әлеге өлкәдә шактый зур эш башкара.

Президент, бу сүзләрен раслау өчен, Татарстанның ЮНЕСКО исемлегенә кертелгән өч объектына – Казан Кремле, Болгар һәм Зөя утрау-шәһәрчегенә аерым тукталды. Аларның тарих, архитектура һәм мәдәният һәйкәлләре буларак кына түгел, тынычлык һәм татулык сәясәтен ныгыту өчен яңа мөмкинлекләр ача торган объектлар буларак та билгеле булуын искәртте.

– ЮНЕСКО принципларына һәм идеалларына тугры калып, без аның консультатив органнары белән хезмәттәшлекне дәвам иттерергә ниятлибез. 2020 елда Россия ЮНЕСКО исемлегенә яңа объект – Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләрен кертүне тәкъдим итте. Бу – Татарстан өчен генә түгел, гомумән, илебез өчен уникаль күренеш. Моңа кадәр Россиядә фәнгә бәйле мөстәкыйль номинацияләр юк иде, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов.

Моннан тыш, Президент Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган чараларның Россия һәм мөселман дөньясы арасындагы хезмәттәшлекне ныгытуын ассызыклады.

– Россия Президенты кушуы буенча әлеге юбилей датасы федераль дәрәҗәдә билгеләп үтелә. Аның кысасында төрле әһәмиятле проектлар, шул исәптән чит ил кунаклары катнашындагы чаралар узды. Бу исә мөселман дөньясының мәдәният, тарих, дин өлкәсендә Россия белән хезмәттәшлеген үстерүгә әһәмият бирүен раслый, – диде ул. – Республикада мәдәни мирасны саклау буенча эш туктап тормый. Без Казанга һәм, гомумән, бөтен православие дөньясына совет хакимияте елларында юкка чыгарылган тарихи гыйбадәтханәне кайтардык – Казан Изге Ана иконасы соборын торгыздык. Бай дини мирасыбыз, төрле булуыбызга карамастан, бердәмлегебезне исбатлый. Бүген без мәчетләрдә һәм гыйбадәтханәләрдә дога кылып, илебезне яклау юлына басабыз. Милли һәм дини дошманлык орлыклары чәчәргә омтылучылар берни дә эшли алмаячак. Без беркайчан да иманыбыз һәм традицион кыйммәтләребездән, барлык халыкларга, мәдәниятләргә хөрмәтебездән, Ватаныбызга мәхәббәттән баш тартмаячакбыз!

Сәясәттәге кыенлыклар – вакытлы күренеш. Рөстәм Миңнеханов чыгышын әнә шундый сүзләр белән тәгәлләде.

– ЮНЕСКОның төп принциплары һәм әлеге форум кысасындагы аралашу безгә бер-беребезне янәдән ишетергә һәм аңларга ярдәм итәр дип уйлыйм. Безнең форум берләшү, каршылыкларны җиңү, үзара хезмәттәшлекне яңа дәрәҗәгә күтәрү бурычына хезмәт итсен иде, – диде Президент.

Ахыры 2 нче биттә >

Фикер

Сергей ОРДЖОНИКИДЗЕ, Россиянең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе җаваплы сәркатибе:

– Көнбатыш илләре безгә ЮНЕСКО комитетының 45 нче сессиясен үткәрергә мөмкинлек бирмәде. Шуңа да без, аларга җавап йөзеннән, Конвенциянең 50 еллыгы уңаеннан форум уздырырга карар кылдык. Зур әһәмияткә ия документның юбилей елында бу – бердәнбер чара.

Айрат СИТДЫЙКОВ, Татарстан Фәннәр академиясенең Археология институты директоры:

– Әлеге форумның бездә узуы Татарстанның Россия дәрәҗәсендә генә түгел, дөнья күләмендә тоткан урынын билгели, аның тарихи мирасны саклау өлкәсендә гаять зур әһәмияткә ия эш башкаруын раслый. Ә инде Казанга төрле илләрдән экспертлар җыелу бездәге тарихи һәйкәлләрнең халыкара әһәмияткә ия булуы турында сөйли. Әлеге форумның, мәдәни мирас өлкәсендәге мөһим мәсьәләләрне күтәреп, булган проблемаларны хәл итү өчен этәргеч ролен үтәвенә ышанам.

Яңа пособие

3 яшькә кадәрге балалары булган ата-аналар ана капиталыннан айлык пособие алырга мөмкин. Аның күләме бер яшәү минимумына тигез булачак.

Россия Президенты Владимир Путин бу җәһәттән тиешле законга кул куйды. «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» һәм «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» законнарга үзгәрешләр кертелгән. Өстәмә акча алу мөмкинлегеннән бер кешенең уртача кереме ике яшәү минимумы күләменнән артмаган гаиләләр файдалана алачак.

Арттырганнар

Татарстанның нефть компанияләре, гыйнвардан октябрь аена кадәрге чорда «кара алтын» чыгару күләмен узган елдагы белән чагыштырганда 3,7 процентка арттырып, 29,6 миллион тоннага җиткергән.

Татарстанстат мәгълүматларына караганда, быел 10 ай эчендә шулай ук 775,3 миллион кубометр иярчен нефть газы табылган. Анысы алдагы елдагыдан 6,9 процентка күбрәк.

Республикада гыйнвар – октябрь чорында якынча 2,4 миллион тонна бензин җитештерелгән. Узган елдагыга караганда 1,5 тапкыр зуррак сан бу. Моннан тыш 9,4 миллион тонна дизель ягулыгы (2021 елдагыдан өчтән бер өлешкә күбрәк) эшләп чыгарылган. Тулаем алганда, шушы чорда Татарстанда нефть эшкәртү күләме 15,5 миллион тоннага җиткән. Бу күрсәткеч узган елдагы белән чагыштырганда 15,3 процентка күбрәк.

Алданалар

Белгечләр сак һәм игътибарлы булырга киңәш итә. Яшел Үзәндә 57 яшьлек хатын-кыз, полиция бүлегенә килеп, ниндидер кешеләрнең 3 көн буе шалтыратып торганнан соң акчасын урлаулары турында сөйләгән. Үзләрен полиция хезмәткәре дип таныштырган ир-атлар аңа карата җинаять эше кузгатылуын һәм мәгълүматлары ярдәмендә кемнеңдер башка илгә акча күчерүен әйткән. Куркуга калган хатын-кыз башта банктагы акчасын, аннан тагын ике кредит алып, ул акчаны да мошенниклар әйткән счетка күчергән. Зыян күләме 4 миллион сум чамасы тәшкил иткән. Алданганын ул хокук сакчыларына мөрәҗәгать иткәч кенә аңлаган.

Казанда мошенниклар 76 яшьлек хатын-кызны алдаган. Туганының бәлагә юлыгуы турындагы сүзгә ышанып, ул 300 мең сум акчасыннан коры калган. Изге күңелле пенсионер, акчасын банктан алып, курьерга биреп җибәргән. Башкалада яшәүче 42 яшьлек хатын-кыз да шул ук суммадагы акчасын югалткан. Аңа шалтыраткан билгесез кешеләр үзләрен банк хезмәткәре дип атаган һәм ханымның картасыннан кемнеңдер акча алырга маташуын әйткән. Бурычын каплау өчен аны кредит алырга һәм акчаны әйткән счетка күчерергә күндергәннәр.

Җылыта

Татарстанда суык антициклон хөкем сөрә. Декабрь өчен гадәттән тыш саналучы суык атна ахырында гына чигенә башлаячак. Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, тәүлеклек уртача температура нормадан 10–15 градуска түбәнрәк. Шулай ук атмосфера басымы да тиешледән югары: Казанда терекөмеш баганасының 780 миллиметрына кадәр күтәрелгән.

Һава торышы 9 декабрьгә кадәр үзгәрми. Явым-төшем көтелми. Көндез –10...–15 градус суык. Төнлә температура –15...–20, урыны белән –20...–26 градуска кадәр төшәчәк. Җомгада –7...–12 градус булыр дип көтелә. Юлларда бозлавык саклана. Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, шимбә – 10 декабрьдә бераз җылыта башлаячак. Төньяк-көнбатыштан циклон үтеп керү сәбәпле, кар явачак. Көндез температура –4...–9, төнлә –7...–12 градус.

Татарстанга килегез!

Агыла да... кунак агыла

Тиздән Тәтештә туристлар саны тагын да артачак. Киләсе елда биредә «Түбәтәй Tower» күзәтү манарасын төзеп бетерергә ниятлиләр. Идел буйлап хәрәкәт итүчеләрне «Бөек Идел юлы» да көтә. Ә республиканың елга-күл буйларында яңа комлыклар пәйда булачак. Рәхәтләнеп ял итегез!

Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов республикада «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проектын тормышка ашыру нәтиҗәләре һәм алдагы эшләр турында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, туризмны үстерүгә быел 16 миллион сумга якын субсидия бүлеп бирелгән. Әлеге акчаның 13 миллион сумы ил казанасыннан алынган.

Инде күптән тел очында йөргән «Түбәтәй» күзәтү манарасын, ниһаять, Тәтештә төзи башлаганнар. Хәтерләсәгез, биеклеге 100 метрдан да артып китәчәк корылманы моннан ике-өч ел элек үк башкалада сафка бастырырга җыендылар. Аның урыны да сайланды. Күзәтү манарасы «Ак Барс Арена» янында калкып чыгарга тиеш иде. Аннары аны Биектауда төзү турында сүз чыкты, ахыр чиктә Тәтешкә тукталдылар. «Күзәтү манарасы киләсе елга төзелеп бетәчәк», – диде Сергей Иванов. «Түбәтәй» Идел ярыннан туристларны җәлеп итеп торачак.

Киләсе елда Татарстанда бөтен уңайлыклары булган комлыклар да артачак. Моның өчен ил бюджетыннан 143 миллион сум акча бүлеп биреләчәк. Тагын 34 миллион сум акчаны республика өстәячәк. «Татарстанда бөтен кешегә дә комлыкларда урын җитми. Киләсе елда елга-күл буйларында комлыклар төзүгә бәйле 18 проектны хупларга җыенабыз. Лаеш районындагы «Кама диңгезе» кадәр үк зур булмасалар да, яңалары рәхәтләнеп ял итү, су коену урыннарына әвереләчәк. Кызынырга ике-өч ай вакыт бар», – диде комитет җитәкчесе.

Сергей Иванов «Бөек Идел юлы» төбәкара туристик маршрутына да аерым тукталды. Ул Идел буйлап сәяхәт итүне күздә тота. «Әлеге юнәлештә Россия Президенты Владимир Путин дәрәҗәсендә йөкләмәләр бирелде. Бу – мөһим проект. Идел буйлап яңа озын маршрутлар барлыкка киләчәк. Бездә туристларга күрсәтерлек әйберләр җитәрлек. Төрле халыкларның мәдәнияте дисеңме, тарихи объектлар, шәһәр үзәге буйлап сәяхәт – болар барысы да кунакларның игътибарын җәлеп итәчәк», – дип сөйләде Сергей Иванов. Дөрес, әлеге юнәлештә эш тә җитәрлек. Иң элек яр буен тәртипкә китерергә кирәк. «Ничек кенә булмасын, башка төбәкләр белән чагыштырганда безнең хәлләр яхшырак», – диде Сергей Иванов. Аның фикеренчә, туристларны чакырганчы суднолар җитмәү мәсьәләсен дә хәл итәргә кирәк. «Җәй көне билетлар, гомумән, калмый. Идел буйлап сәяхәт итәргә теләүчеләр саны арта, ә аларны юлга алып чыгарга мөмкинлек юк», – диде комитет җитәкчесе. Хәзер Чабаксардан Казанга су буйлап сәяхәт итеп була, киләсе елда Түбән Новгород һәм Чабаксар арасында «күпер» салыначак дип көтелә. Суднолар мәсьәләсе хәл ителсә, «Бөек Идел юлы» өч-дүрт елдан тормышка ашачак, дип фаразлады Сергей Иванов.

Форсаттан файдаланып, комитет җитәкчесеннән Яңа ел кәефе турында да сорадылар. Казан Яңа ел бәйрәмнәрендә ял итү өчен иң кыйммәтле шәһәрләр исемлегенә эләккән. «Кыйммәтлене дә сатып алалар икән, димәк, бар да яхшы, – диде Сергей Иванов. – Кунакханә хуҗаларының башы эшли. Сорау зур булгач, бәяләр дә үсә». Ял да итә белергә кирәк шул. Шөкер, Татарстан халкына артык түлисе юк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сүзгә-сүз

Наил МӘҺДИЕВ, Чаллы мэры:

Минем бу соравыма җавап бирегез әле: бер кило балык кеше гомеренә торамы? Гомернең бәясе шулмы? Балыкчы балаларын, гаиләсе, хатыны, оныклары, туганнары, якыннарын калдырып китеп бара. Мәһдиев яшәргә өйрәтә, дияр күпләр. Мин берәүне дә яшәргә өйрәтмим, ничек телисез – шулай яшәгез. Әмма болай да ярамый. Боз өстенә чыкмый торыгыз. Яңа тотылган балыкны базардан да алып була.

(«Челнинские известия»)

ТАТАРСТАНДА – АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Быелның 10 аенда Татарстанның авыл хуҗалыгы оешмалары 122 млрд сумлык продукция җитештергән.



1 млн 264 мең тонна сөт........................**38,8 млрд сум**
342 мең тонна терлек һәм кош ите......**40,9 млрд сум**
1 млрд 28 млн данә йомырка..................**5,4 млрд сум**

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 җомга саны — **Ташламалы бәя** **444 сум 54 тиен** (гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~)

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — **Ташламалы бәя** **980 сум 10 тиен** (гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~)

Реклама 16+



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ФЕТНӘ ҺӘМ ЧИГЕНҮ

Глобаль кризис фронтыннан атна саен яңа хәбәрләр килеп тора. Канаданың үзәк банкы үз тарихында беренче тапкыр зыянга эшләде дигән хәбәрләр алынды. Быелның өченче кварталында ул 522 миллион доллар күләмендә акча югалткан. Илдә соңгы кырык елда күрелмәгән инфляция котырына. Шуны авызлыклыйм дип, Үзәк банк процент ставкасын бик югары күтәргән һәм, депозитларга түләүләр арту сәбәпле, табыш урынына зыян күргән. Игътибар итегез: бу хәл 2008 елгы кризиста да, аннан алдагы түнтәрелешләрдә дә күзәтелмәгән.

Нигериядә ААХ криптобиржасы клиентлары, аның җирле офисларына бәреп кереп, хезмәткәрләрен кыйнап ташлады. Криптобиржалар белән бәйле беренче фетнә мәйданга чыкты. Алдагы айларда андый хәл торган саен күбрәк күзәтелер, мөгаен, чөнки криптобизнесның чылбыр реакциясе рәвешендәге түнтәрелеше көчәя. Яңа гына газета хәбәрчесе Ноо дип аталган Гонконг биржасының үз сайтын юк итүе хакында мәгълүмат алды. Клиентлар ул биржага керткән акчасын ала алмыйлар. Сүзнең ничә миллиард доллар турында баруы әлегә билгесез.

Үткән атнаның төп билгесе Кытай протесты булды. Чин илендә күндәм генә иелгән башлар беренче тапкыр югары күтәрелделәр һәм ковид-чикләүләргә каршы фетнә башланды. Рәсми Кытай хакимиятләре, бернинди дә баш күтәрүләр юк, дип әйтергә тырышса да, гыйсъянчылыкның кайнар ялкыны тышка ук бәреп чыкты. Дөрес, дөнья матбугаты сурәтләгәнчә үк массакүләм баш күтәрүләр юк, әмма сәяси лозунглар күтәреп чыккан фетнәчеләр чин иле өчен ярыйсы ук күп санлы. Компартия бу юлы зур кан түгүле чаралар үткәрүдән сакланды, фетнә учаклары булган Өремче, Гуаньчжоу, Шанхайда ковид-чикләүләр йомшартылды. Кытайның нуль-ковид сәясәте гаҗәп кызык бит инде ул: көрәш катгыйрак барган саен, пандемия ныграк котырына. Күрәсең, сүз медицина турында түгел, сәясәт хакында бара. Хәзер мәгълүмат кырында Кытайның халыкларны богаулап тоту буенча дөньякүләм тәҗрибә полигоны булуын раслаган хәбәрләр шактый. Уңышлы гына барган тәҗрибә чигенү этабына килеп керде. Европада һәм Америкада, пандемияне сылтау итеп, авызлык кидерү сәясәте үткән елда ук төгәлләнде.

Шактый ук зур куәт белән башланып киткән Иран фетнәсе дә соңгы көннәрдә йомшак чишелеш белән төгәлләнергә әзерләнә. Иран хакимиятләре протестны бастыру өчен Россиядән ярдәм сорады дигән рәсми булмаган мәгълүмат күренде. Аны «Iran International» – штаб-квартирасы Лондонда булган яңалыклар телеканалы тарата. Әмма ул илдә гыйсъянчылар чыгышлары сан ягыннан да, ярсулыгы буенча да кимү-сүрелү ягына бара. Иран хакимиятләре әхлак полициясен бетерделәр дигән мәгълүмат та таратылды. Ләкин җирле Иран матбугаты моны кире кага. Чит ил мәгълүмат чаралары илнең генераль прокуроры Мөхәммәд Җәфар Монтазериның сүзләрен бозып күрсәтә, дип белдерә «Al Alam» дигән телеканал. Әмма шулай да Иран җитәкчелеге дә, бернигадәр чигенеп, фетнәне прәннек белән бастыру юлын эзли төсле.

Россиядә

НЕФТЬ «ТҮШӘМ»Е ТИРӘСЕНДӘ ТАРТЫШ

Россия нефть тармагы ике катлы санкцияләр тозагына эләкте. 5 декабрьдән Европа берлеге керткән «кара алтын»га эмбарго эшли башлый, 2023 елның 5 февраленнән нефть продуктларына да чикләү кертелә. Озак бәхәсләшкәннән соң, Көнбатыш илләре, ниһаять, Россия сата торган җир маеның түшәм, ягъни иң югары бәясен килештерделәр: 60 доллардан артырга тиеш түгел.

Чикләү диңгез танкерлары аша сатыла торган нефтькә генә кагыла. Торбадан агылган «кара алтын» базар бәясендә кала. Европада хәзер Венгрия генә «Дуслык» нефть үткәргеченнән файдалана, димәк, венгрлар «түшәм»сез бәядән файдалана. Польша чик бәяне 30 доллар гына итеп куюны таләп иткән иде, аның формуласы кире кагылды. Россия ноябрь ахыры – декабрь башында үз чималын 48–55 доллардан озатты. 60 долларлык чик бәя, бу күзлектән караганда, начар түгел төсле. Әмма 2023 ел бюджетына нефть бәясе – 70 доллар, доллар курсы 68 сум тирәсе булыр дип тәгаенләнгән. Бу җәһәттән саннар берсе дә бюджет параметрларына туры килми, димәк, керемнәр азрак булачак дигән сүз.

Кремль, билгеле, «түшәм»не танымый, аны таныган илләргә «кара алтын» сатудан баш тартачагын игълан итә. Мәскәүдә шундый позиция җир маена бәяне чиксез күтәрер һәм Көнбатыш оттырыр дип исәп тоталар. Моңа җирлек тә бар иде шикелле, чөнки 4 декабрьдә ОПЕК+ илләре җыелып, нефть чыгаруны киметү турында килешер дигән өмет яшәде. Өмет чынга ашса, чынлап та, көнбатышлылар өчен авырга туры килер иде. Тик ОПЕК+ бу юлы Мәскәүгә җилкәсен куймады: «кара алтын» чыгару күләмнәрен элеккечә калдырды. Бу эшне катлауландыра. Нефть картелен җитәкләгән гарәп илләре вазгыятьне сынап карарга булдылар. Алар февральдә генә яңадан җыелачак. Шунда, базардагы хәлгә карап, яңа карар кабул ителер, дип килештеләр.

Россия өчен катлаулы хәл туды. «Түшәм» турында килешкән илләр февральгә кадәр Россия нефтенең 70 процентын кулланалар иде. Ул кадәр күләмне сатудан туктау зур югалтуларга китерәчәк. Барлык нефтьне дус дип саналган Кытай, Һиндстан һәм Төркиягә озатып булмаячак. Бердән, моның өчен кирәкле инфраструктура юк. Икенчедән, чималны күпкә еракларак ташу транспорт чыгымнары арту белән китереп сугачак. Белгечләр 20–30 долларлык өстәмә чыгымнар туачагын әйтә. Өченчедән, «дус» илләр, Мәскәүнең чарасыз калуыннан файдаланып, ташлама таләп итәчәк. «Түшәм»нән дә югарырак сатып булмас барыбер. Тагын бер нәрсәне истә тотарга кирәк: нефть эшкәртү заводлары аерым сорт чималны эшкәртүгә көйләнгән. Россия нефтенә күчү Азиядәге заводларны үзгәртеп коруны таләп итә. Көчәеп килүче кризис чималга ихтыяҗны киметәчәк, бу факторны да онытырга ярамый. Әлегә 19 гыйнварга кадәр элек төзелгән килешүләр буенча нефть озатылачак. Менә шул датадан соң Россиядә нефть чыгару катастрофик темплар белән кимергә мөмкин. «Түшәм» белән килешеп сата башламасалар инде.

МИРАС ТИРӘСЕНДӘ БЕРЛӘШҮ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яшьләргә – юл

Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКО илчесе Минтимер Шәймиев мәдәни һәм табигый мирасны саклау өлкәсендәге республика тәҗрибәсе турында сөйләде. Татарстанның өч объектын ЮНЕСКО исемлегенә кертүдә мөһим рольләрнең берсен уйнаган кеше буларак, ул һәр объект тарихына һәм аның безнең көннәргә ни рәвешле килеп җитүенә аерым тукталды.

– Мөселман һәм православие динен тотучыларның изге урыннарын бер үк вакытта торгызу – вакыт белән сыналган карар. Моның әһәмиятен кешеләр дә аңлады. Һәм бу карар ЮНЕСКОның мәдәни күптөрлелек һәм әхлакый кыйммәтләрне саклау принцибына тулысынча туры килә, – диде Минтимер Шәймиев.

Моннан тыш ул Конвенциянең мәдәни һәм табигый мирасны киләчәк буынга тапшыруның, беренче чиратта дәүләт бурычы булуы турында язылган дүртенче маддәсенә аерым тукталды.

– Мирасыбызны яшь буынга тапшырганда, без аларның эшебезне дәвам иттерә алуына ышанырга тиеш. Ягъни аларны үз мирасын белә, ә иң мөһиме – тиешле дәрәҗәдә бәяли ала торган итеп тәрбияләү мөһим. Шуңа күрә республикада рус, татар һәм инглиз телләрен укытуны максат итүче полилингваль белем бирү комплексларын төзү буенча масштаблы проект гамәлгә ашырыла. Без бу комплексларны «Адымнар – белем һәм татулыкка юл» дип атадык. «Адымнар»да балалар ЮНЕСКО принциплары нигезендә тәрбияләнә, – диде республиканың Дәүләт Киңәшчесе.

Сүз уңаеннан, әлеге форум кысасындагы Яшьләр моделе Минтимер Шәймиев телгә алган «Адымнар» комплексында узачак. Аның төп максаты – яшь буынны Конвенция һәм ЮНЕСКО принциплары белән таныштыру, бу өлкәгә мәктәп укучыларының игътибарын җәлеп итү, әлеге тема буенча фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу.

Бернигә дә карамый

Бөтендөнья табигый һәм мәдәни мирасны саклау конвенциясенең 50 еллыгына багышланган халыкара форумны Татарстанда уздыру – бик гадел карар, чөнки нәкъ менә монда мәдәни һәм рухи мираска аеруча зур игътибар бирелә. Россиянең мәдәният министры Ольга Любимова чыгышын нәнә шул сүзләрдән башлады. Аның фикеренчә, Татарстанның дөнья күләмендә танылган объектлары – уникаль урыннар.

Министр шулай ук, ЮНЕСКОны сәясәтләштерү нәтиҗәсендә, Татарстан башкаласында узарга тиешле 45 нче сессиянең булмый калуын искә төшерде.

– Бу – безнең карар түгел. Россия һәм, аерым алганда, Мәдәният министрлыгы аралашу һәм хезмәттәшлеккә һәрвакыт әзер. Әлеге форум моны тагын бер тапкыр исбатлый, – диде Ольга Любимова.

Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров исә, форумда катнашучыларга сәлам хаты аша мөрәҗәгать итеп, Россия мәдәнияте һәм аның аерылгысыз өлеше булган бөек татар мәдәниятенең дөнья цивилизациясе үсешенә зур өлеш кертүен ассызыклады. Аның сүзләрен урынбасары Сергей Вершинин җиткерде.

– Бөтендөнья мәдәни һәм табигый мирасны саклау турында конвенция ул –халыкара әһәмияттәге мәңләгән һәйкәлне саклап кала алган уникаль документ. Казандагы очрашу нәтиҗәләре менә шушы документ кысасында халыкара хезмәттәшлекне үстерүгә ярдәм итәр дип ышанам, – диелгән иде хатта. – Россия мәдәнияте һәм аның аерылгысыз өлеше булган бөек татар мәдәнияте дөнья цивилизациясе үсешенә зур өлеш кертте. Ничек кенә тырышсалар да, әлеге фактны берәү дә инкарь итә алмас.

Татарстанга килгән чит ил кунаклары исә республикага карата соклану хисләрен яшерми. Әйтик, Кытай Халык Республикасының ЮНЕСКОдагы даими вәкиле Ян Цзинь, дөньядагы вазгыятьнең катлаулы булуына карамастан, Татарстанга килүенә бик шатлана икән.

– Татарстан таң калдырды. Россиягә әле беренче генә тапкыр килүем. Монда мине берсеннән-берсе чибәр туташлар ипи-тоз һәм чәкчәк белән каршы алды, – дип, хисләре белән уртаклашты ул. – Нинди генә катлаулы чорда яшәсәк тә, ЮНЕСКОның күпкырлы эшчәнлеге халыкара хезмәттәшлекне дәвам иттерергә мөмкинлек бирә. Россия һәм Кытай халыкара бергәлекнең җаваплы әгъзалары булып тора. Шуңа да без дөньяны 2030 елга кадәр куелган максатларга ирешүгә этәрә алабыз.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сорау һәм җавап

Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин партия Рәисе Дмитрий Медведевның төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегендә кешеләрнең үтенечләрен тыңлады.

Иң элек Дәүләт Советы Рәисенә «Суровка» территориаль иҗтимагый үзидарә (ТОС) рәисе Резедә Шмелева урамны яктырту мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать итте. Суровкада яшәүчеләр авыл башында яктырткычлар урнаштыру тәкъдиме белән төрле инстанцияләргә хатлар юллаган. Резедә ханым әйтүенчә, авыл тиз үсә, автомобиль хәрәкәте көчәя, шуңа күрә караңгыда Суровкага керү кыенлаша. Җитмәсә, янәшәдә генә җәмәгать транспорты тукталышы урнашкан. Фәрит Мөхәммәтшин мәсьәләнең Тукай районы хакимияте белән берлектә хәл ителәчәген әйтте.

Зур Кукмарадан Фәридә Әхтәмова авылда яшәүче барлык халык исеменнән гозерен җиткерде. Елга аръягы урамы аша узучы юлны төзекләндерү мәсьәләсе байтактан хәл ителмичә килә икән. Биредә транспорт күп йөри. Фәрит Мөхәммәтшин муниципалитет белән элемтәгә керде. Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы Рифат Хәнәфиев әйтүенчә, һәркемгә мәгълүм мәсьәлә бу, һәм аны киләсе елда үзара салым акчасына хәл итү күздә тотыла.

Татарстанның атказанган укытучысы Рәмзия Әхмәтова Актаныш районы Уразай авылында яшәүчеләрне эчәр су белән тәэмин итү һәм торак пунктка илтүче асфальт юлны төзекләндерү мәсьәләләрен күтәрде. Ике мәсьәлә дә игътибарга алынды.

Казан автотранспорт техникумы укытучылары һәм студентлары исә Фәрит Мөхәммәтшинны үзләренә кунакка чакырды. Дәүләт Советы Рәисе ризалыгын бирде.

ДЕПУТАТЛАР «КАЙНАР ЛИНИЯ» ҮТКӘРӘ

Пәнҗешәмбе – 8 декабрьдә республикада хатын-кыз эшмәкәрләр өчен бизнес алып баруга бәйле мәсьәләләр буенча «Хатын-кыз игътибары» «кайнар линия»се эшләячәк.

Сорауларга Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» депутатлар берләшмәсе әгъзалары, шулай ук министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре җавап бирәчәк.

«Кайнар линия» телефоны: 8(843)238-10-00. Шалтыратулар 12.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

ТАБЫН ХАКЫ

«Быел берни әзерләмим, булганы белән генә бәйрәм итәм». Яңа ел җитәрәк, еш телгә алына торган сүзләр бу. Ашаган белми, тураган белә шул. Бәйрәм табыны кесәне яхшы ук бушата ул. Шуңа да алдан хәстәрен күрергә туры килә. Белгечләр Яңа ел бәйрәменә кадәр алдан алып куярга кирәк булган азык-төлек исемлеген тәкъдим итә.

Узган ел белән чагыштырганда, быел Яңа ел өстәле 12–14 процентка кыйммәтләнәчәк. Бу хакта белгечләр уздырган сораштыру һәм Росстат мәгълүматлары сөйли. Шулай да кайбер азык-төлек бәяләренең узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда күпкә арзанрак булуын да искәртәләр.

Табын мәшәкатьләрен алданрак кайгыртырга кирәк, ди белгечләр. Яңа елга бер ай кала кибет киштәләрендә азык-төлек тә күбрәк, сайлау мөмкинлеге дә зуррак, бәяләр дә тешләми торган була бит. Бу очракта кеше ике куянның койрыгын бер юлы тотачак: янчыктагы акча да азрак сарыф ителәчәк, ашыгып йөрергә дә туры килмәячәк.

«Здоровое-питание.рф» хезмәте хәбәр иткәнчә, консервланган азык-төлекне хәзердән үк алып куярга мөмкин. Мәсәлән, кукуруз, яшел борчак, тозланган яшелчәләр, зәйтүн.

Эчемлекләр турында да алдан уйларга кирәк. Сок, шәраб һәм башкаларга бәя, Яңа ел җитәрәк, бик күпкә кыйммәтләнәчәк. Белгечләр әйтүенчә, эчемлекләрне алдан алып кую – шактый акчаны янга калдыруның бер яхшы ысулы да.

Моннан тыш үсемлек мае, майонез, он, тоз, шикәр комы, ярмалар, төрле тәмләткечләр, йомырканы да алдан алып куярга мөмкин. Соңгысын сатып алганда игътибарлы булыгыз: куллану вакыты бәйрәм сәгатьләре сугар алдыннан чыга күрмәсен. Йомырканы суыткычта саклау мөһим!

Моннан тыш кабымлыклар өчен кирәк-яракларны алдан сатып алырга киңәш ителә. Уылдык, казылык, сыр, балык – аларның бәяләре көнләп күтәрелә. Кем иртәрәк өлгерә, шул акчасын янга калдыра инде. Әмма уяулыкны югалтмагыз: сыйфатсыз товар бәйрәм кәефен тиз бетерәчәк.

Икътисад белгече Татьяна Куликова сүзләренчә, инфляция җиленнән ерак китеп булмаячак. Шулай да Яңа елга бәяләр артык уйнамас, дип өметләнә белгеч. «Әмма 2023 елның беренче яртысы кешеләрнең кесә янчыгына шактый тәэсир итәр. Шуңа да запасларны алданрак, аз-азлап туплап куюның мантыйгы бар. Яңа ел табынына продукциянең кыйммәтләнүе табигый: кешеләр бар нәрсәне дә соңгы мизгелгә калдырырга ярата. Хәзер сатып алырга мөмкинлек бар икән, бу мөмкинлектән файдаланыгыз», – ди ул.

Авыл капкасы

МАЛ ЧАЛУЧЫ:
«ИТНЕҢ ИҢ ШӘП ҖИРЕ – БИЛДӘМӘ»

Авылларда иң күңелле һәм мәшәкатьле чор. Халык тырышып үстергән терлеген чалып, аның әҗерен күрә. Кемдер үзләренә, бала-чагасына дип чалса, кемдер сатарга дип әзерли. Шул уңайдан кызыксындырган сорауларыбызны Балтач районының Кариле авылында яшәүче тәҗрибәле сугымчы, озак еллар бригада белән халыкның малларын чалып йөргән Хәмзә ГАРӘПШИНга бирдек. Алар сатучыга да, сатып алучыга да файдалы булыр дип өметләнәбез.

:: Хәмзә абый, мал ничә яшьтә чалырлык булып өлгерә?

– Үгез малы 1,5 яшьтә чалырлык булып өлгерә. Шуннан соң аның ите тыгызлана, катылана. Тананы 1–1,2 яшьтә эшкәртсәң яхшы. Аннан соң ул симерә башлый. Артык тазарып китеп, итен май каплап алса да яхшы түгел. Ләкин шул ук вакытта майсыз итнең дә тәме булмый. Тана итенең авырлыгы үгезнекенә караганда җиңелрәк килә.

:: Итнең иң тәмле өлеше кай җире?

– Үпкә-бавыр белән эчәкне бүлеп тора торган өлеш – итнең иң тәмле җире. Ул 10–15 минутта пешә. Аннан кала билдәмә (вырезка) – шәп җире. Санлап алганда, малның ал ягы әйбәтрәк. Кеше арт санына кызыга, ләкин алгы өлеше тәмлерәк. Алгы як кабыргалы була. Юка кабырга шулпада бик тәмле булып, кабарып пешә. Арткы ягы – фаршка, алгысы шулпага яхшы. Ите алгы якта да, арткы якта да – бер чама. Алгы якта сөяге азрак та әле. Хәзер эчәкнең мәшәкатеннән куркып, аны ташлаучылар да бар. Югыйсә шулай ук бик тәмле җире бит. Бигрәк тә кырык картасы шәп. Терлек арасыннан карасак, ат эчәге – иң тәмлесе. Шуңа күрә ул ит бәясеннән йөри.

:: Чалыр алдыннан малга нинди игътибар күрсәтәсе? Аерым тәрбия кирәкме?

– Бер тәүлек ашатмаган малның эчәген төшерергә җайлы була. Силос ашаткан малның итеннән ис килә, дип әйтүчеләр дә бар. Миңа калса, аңа карамый ул.

:: Терлек чалучылар турында «кулы тәмле» дип ишетергә туры килә. Ул нәрсәгә бәйле икән?

«ВТ» архивыннан

– Минем үзем турында кешеләр шулай дип әйтә иделәр. Иң беренче шарт – малны кыйблага каратып, өч тапкыр «Бисмилләһир-рахмәәнир-рахиим» дип чалу. Моннан тыш, чалганда озак тонган терлекнең ите тәмле була. Канның чыгып бетүе кирәк. Эш җайлы барсын өчен, сугымчының көчле һәм пычакның шәп үтүе дә мөһим. Чала торган пычак аерым булырга тиеш. Чалырга дип алып чыкканда малны җай белән генә, кыйнамыйча алып чыгарга кирәк. Кайбер мал тумыштан холыксыз, дуамал була. Андыйларга ничек тә җай табарга тырышырга кирәк. Үземне ат тибеп, кулымны сындырганы булды. Куркып калган малның каны организмыннан чыгып бетми, ите каты булырга мөмкин. Алар бит барысын да алдан сизә. Ат – бигрәк тә сизгер җан иясе.

:: Малларны чалырга кызганмыйсызмы?

– Дин ягыннан караганда, кызганып чалган мал дөрес булмый. Шуңа күрә мин аларны кызганмыйм, моңа эш дип кенә карыйм.

:: Итне сатып алганда нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Кызгылт, бераз гына алсу төстәге ит – иң яхшысы. Аннан соң аның мае да булырга тиеш. Ит арасында май җепселләре күренеп торганны курыкмыйча сатып алырга мөмкин. Ә артык куе кызыл һәм зәңгәрсу булып торган ит күңелдә шик уятырга тиеш. Башкорт үгезләренең ите иң яхшысы санала. Алар – ит өчен бик яхшы токым. 1 елда 3,5 центнер ит бирә алар. Ләкин алар арасында холыксызлары күбрәк очрый.

:: Нәрсә ашатсаң, ит тәмле була?

– Чалырга бер ай кала солы, арпа пешереп ашаткан мал яхшы була.

:: Кайбер малның ите каты була. Моның хикмәте нидә икән?

– 6–7 бозау китергән сыерның ите, әлбәттә, каты була. Сыер чалырга җыенсагыз, 1–2 бозаулаганны карарга кирәк. Аның ите җитлеккән, шәп була. Шулпасы да бик тәмле. Тана ите йомшаграк, тәмлерәк, үгезнеке катырак. Шулпада пешкән ат итен яратмаучылар да бар, ә кемдер гел шуны гына ала. Шуңа күрә монда һәркемнең үз теләге.

Арча районының Ашытбаш авылында яшәүче Рәис Шәкүровтан терлек асрауга кагылышлы кызыклы фактлар

- ✓ Иң файдалы ит – сарыкныкы, аннан – атныкы.
- ✓ Холестерин курыккан малларда күбрәк барлыкка килә. Шуңа күрә хайванны куркытып чалырга ярамый. Сарык «минем йонны гына алырга алып чыгалар» дип уйлап, курыкмый икән. Шуңа күрә аның итендә холестерин да азрак.
- ✓ Куркытып суйган малның ите каты була.
- ✓ Иң файдалы тирес – сарыкныкы, аннан соң гына – атныкы. Күпләр ат тиресе дип уйлап ялгыша. Ат тиресенең чамасын югалтсаң, ул җиргә утыртылган яшелчәләрне яндырып, зыян салырга мөмкин. Ә сарык тиресенә утыртылган яшелчәләр гөрләп үсә.
- ✓ Пычракта яткан сарыкның ите исле була.
- ✓ Сарык асрыйсың икән, тәкә ел саен алыштырылырга тиеш, чөнки алты айдан ул үзенең бәтиен каплата башлый. Аннан соң нәсел бозыла.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СУККАЛАП ТА КАККАЛАП...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Кукмара районының Купка авылында 120 хуҗалык исәпләнсә, шуның яртысында итек басу белән шөгыльләнәләр. «Безнең буын бетсә, итекчеләр калмаячак. Беренчедән, эше пычрак. Икенчедән, яшьләргә акча күп керсен», – ди 31 ел итек басучы Нияз Фәтхерахманов. Киез итекләр кемнәрнең аягын җылыта?

Урамда мәчеттән кайтып килүче авыл агайларын очраттык. Аларның аягында да – киез итек. Дөрес, бу яшьтә үзләренең итек басу эшенә көче җитми инде. Шулай да авылдашларыныкын бик яратып кияләр икән. «Итекне остасына карап сайлыйбыз», – диде алар. Чөнки итек басу эшенең серен беләләр. Ниязның итеге катмый да, таралмый да дигәч, нәкъ менә аларның ишеген шакыдык. «Моңарчы берәүнең дә кире китергәне булмады», – диде итекче, елмаеп. Мәрхүм әтисе Фаязның: «Улым, гадел бул, кеше зарланырлык булмасын, әйбәт эшлә», – дигән сүзләрен һәрвакыт истә тота ул. Яхшы итеп басылган итек, көн саен киеп йөрсәң дә, 3–4 елга җитә, ди.

«Бәргәлибез, суккалыйбыз, әйләндерәбез». Нияз әйтүенчә, итек эшенең тәртибе әнә шуннан гыйбарәт. Башта аны тигез итеп түшәргә кирәк. Аннан камыр баскан кебек гел әвәләп торасы.

– Итек башта бик зур була. Эченә агач тыгып, кунычларын эчкә бөкләп, бетон болгата торган җайланмада 30–40 минут әйләндерәм. Бераз керешеп китә. Калганын кул белән «каталка»да эшләп бетерәм, – ди Нияз Фәтхерахманов.

Бер итекне ике сәгать эчендә әзерләргә була. Нияз исә, кәефенә карап, көнгә өч-дүртне баса. Кичтән түшәп калдыра. Бу эштә аңа хатыны Чулпан да булыша.

Менә бу урында яхшы итек турында сорарга җай чыкты. Катырагы әйбәтрәк икән. Йомшагы исә басылып бетмәгән була, бер атнадан җәелеп китәчәк. Киез итек калын табанлы, кунычка таба югарып барырга тиеш. Табаны белән кунычы тигез булса, матур килеп чыкмый. Белгеч безгә әнә шулай дип аңлатты. Кислота кушмыйча да булмый, югыйсә буяганда буяу утырмаячак. Әзер итекне машина мае белән ялтыратып ала икән. Монысы инде җыйнак, матур күренсен өчен. Җылылыкка килгәндә, буямаганы җылырак, ди. Аныкы барысы да – кара төстә. Агын, көлсуын сораучыларны башка итекчеләргә җибәрә.

Бер кашык дегет бер мичкә балны боза, диләр. Итекченең хезмәтен ялгышып кереп калган бер тигәнәк тә харап итәргә мөмкин. Шуңа күрә Фәтхерахмановлар теткән йон сатып алырга тырыша. Аны күрше авылларда килосын 250–400 сумга саталар.

Хәзер сарык асраучы хуҗалыклардан йонны бик очсызга җыялар, акчасы бер кайчы алырга да җитмәгәч, ягабыз гына, диләр. Әгәр йон әйбәт булса, итек басучылар да акчасын кызганмас иде.

– Теләче, Балык Бистәсе районнарына барып җыйган бар. Тигәнәкле йонны кул белән язып утырырга кирәк. Әгәр чиста булмаса, итекне буягач, тигәнәкнең чәнечкесе күренеп кала. Башкортстан йоны әйбәтрәк һәм чистарак. Балалар итегенә – 300–800 грамм, хатын-кызныкына 1 кило йон кирәк, – ди Нияз.

Итеккә соңгы өч елда ихтыяҗ арткан. Ә аңа кадәр бераз кимеп торган. Итекче моның сәбәбен әйтә алмады. Иртәнге якта ук Фәтхерахмановларга чират җыелган вакытлар да була. Пермь крае, Свердлау өлкәсе, Башкортстан алыпсатарлары күмәртәләп алып китә торган булган. Хәзерге вакытта читтән килүчеләр күренми. Әмма итекләре киштәдә тузан җыеп та ятмый. Күрше авыллар чит төбәкләргә алып барып саталар икән. Бәягә килгәндә, бер пары – 1200–1500 сум.

Тырышсаң, табышы да бар. Өй җитештергәндә дә файдасы тигән, тормышны алып бару өчен ярап куя. Нияз өчен сезонлы эш бу. Итек цехына сентябрьдә керсә, аннан мартта гына чыга. Көнгә 7–8 сәгать вакыты шунда үтә. Парлы мунчада, ишекне ачып, итек басу сәламәтлеккә файдага түгел. Туеп киткән чаклары да була Ниязның. Тик, туеп, кая барасың? Элек шабашкага йөргәләгән. Абзар тулы мал-туар. Сигез сыер, бозау, сарыклар асрыйлар. Аларны да карарга кирәк. 8 гектар җирләре бар. Җәй көне басуда бәрәңге, суган, кишер үстерәләр, малларга печән әзерлиләр.

Армиядән кайткач, өйрәнгән һөнәрен әле дә онытмый гаилә башлыгы. Үзе исә белгәнен улларына өйрәтәме икән?

– Олы улым Илназ, Саба агрокөллиятен тәмамлап, армиядә хезмәт итеп кайтты. Хәзер өйләнеп, Казанда яшиләр. Искәндәр күрше авылда – мал табибы. Икесе дә кечкенә вакытта янымда бөтереләләр иде. Итек басып караганнары юк. Өйрәтеп калдырсаң, әйбәт тә инде. Дөньяның кая барганын белеп булмый бит. Кирәге чыгарга мөмкин, – ди Нияз Фәтхерахманов.

Сәрия МИФТАХОВА

Фәтхи Бурнаш

Газетаның тарихын булдырган шәхесләрне барлыйбыз. Фәтхи Бурнаш 1921–1923 елларда баш мөхәррир булып эшли. Аны 1940 елның 24 августында Югары Осландагы җәйге дачасында язып-эшләп утырган җиреннән алып китәләр. Тикшерүләр, сорау алулар 1941 елның гыйнварына кадәр дәвам итә. Әдипне милләтчелектә, әсәрләре белән «солтангалиевчелек» идеяләрен таратуда, аларга матди ярдәм күрсәтүдә гаеплиләр.

Беренче адымнар

Күренекле драматург, шагыйрь, публицист, әдәбият тәнкыйтьчесе һәм тәрҗемәче Фәтхи Бурнаш (Фәтхелислам Закир улы Бурнашев) 1898 елның 13 гыйнварында элекке Сембер губернасының Буа өязе (хәзерге Чувашия Республикасының Батыр районы) Кыр-Бикшик авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белемне алганнан соң, 1907 елда әтисе аны Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә илтеп урнаштыра. Ул заманның күпчелек татар шәкертләре кебек үк, Фәтхелислам да мәдрәсәнең югары сыйныфларында үз көнен үзе күреп укый: җәйләрен казакъ далаларында мөгаллимлек итә яки, Мәкәрҗә ярминкәсенә барып, төрле яллы эшләрдә эшләп, үзенә кыш киенер өчен матди якны кайгырта торган була. 1916 елда ул, мәдрәсәдә алган гыйлеме өстенә, үзлегеннән хәзерләнеп, Казандагы Татар укытучылар мәктәбе программасы буенча экстерн тәртибендә имтихан тота һәм татар мәктәпләрендә рус теле укытучысы булып эшләү хокукы биргән таныклык ала. Фәтхи Бурнашның әдәби иҗат юлындагы беренче адымнары «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган шәкертлек елларына карый.

Большевикларны үз итә

1917 елның маенда аны солдат хезмәтенә чакыралар. Сентябрьгә кадәр Сембер шәһәрендәге пехота полкында хезмәт иткәннән соң, укытучы буларак, ул хәрби хезмәттән азат ителә һәм, шул төбәктә калып, берникадәр вакыт Буа, Сембер шәһәрләрендә мөгаллим, аннары төбәк шәкертләре җәмгыяте идарәсендә сәркатип булып эшли. Октябрь түнтәрелешен һич икеләнмичә, бөтен җаны-тәне белән ихластан үз итеп каршы ала. Бик дәртләнеп-илһамланып, көндәлек матбугатта язышa, газета редакцияләрендә эшли. 1918 елның апрелендә аны РКП(б)ның Сембер губерна комитеты карамагында чыга торган «Көн» исемле татарча газетага мөхәррир итеп билгелиләр. Шунда эшләгәндә ул, баш күтәргән чехсловак, акгвардияче гаскәрләр кулына эләгеп, тарихта «үлем эшелоны» исеме белән мәгълүм тоткыннар поездында Себер якларына озатыла. Фәкать үзенең кыюлыгы аркасында гына, юлда барганда поезддан качып, үлемнән котыла һәм аклардан азат ителгән Сембер шәһәренә әйләнеп кайтып, «Таң» (элеккеге «Көн») газетасында эшләвен дәвам иттерә.

1920 елда Фәтхи Бурнаш Казанга килеп төпләнә һәм 1924 елга кадәр башта Мәркәз мөселман хәрби коллегиясе органы булган «Кызыл Армия», 1921 елдан «Татарстан» (бүгенге «Ватаным Татарстан») газеталарының җаваплы мөхәррире булып эшли. Бер үк вакытта «Безнең байрак» газетасын, «Чаян», «Безнең юл» журналларын оештыруда һәм чыгаруда якыннан катнаша. 1922 елда аны Татарстан Үзәк Башкарма Комитетына (ТҮБК) әгъза итеп сайлыйлар.

Партиягә каршы төркем

Егерменче елларның урталарына таба Фәтхи Бурнашның әдәби иҗат уңышлары рәхимсез тәнкыйть утына тотыла башлый. Аны милләтчелектә, «буржуаз карашларны әдәбиятка сөйрәп кертүдә» гаеплиләр, «әдәби суд»лар оештыралар.

1924 елда Татарстан хөкүмәте һәм партия өлкә комитетының җитәкче даирәләреннән утыз тугыз кеше, Татарстандагы икътисади һәм сәяси хәлләрне аңлатып һәм җитешсезлекләрне төзәтү өчен конкрет тәкъдимнәрен бәян итеп, Иосиф Сталин һәм Үзәк Комитет исеменә күмәк хат җибәрәләр. Хат Үзәк Комитет тарафыннан кискен тәнкыйтьләнә, «оппортунизм күренеше» дип, ә хатка кул куючылар «партиягә каршы төркем» дип тамгалана. Имза куючылар арасында Фәтхи Бурнаш та була. Хатка кул куючыларны эзәрлекләү, эш урыннарыннан алу, партиядән чыгару башлана. Соңга таба аларның барысы да «солтангалиевчеләр» дип аталып, күпчелеге совет ГУЛАГында һәлак була.

Кулга алынгач та, җинаять эшен карарга тиешле Татарстан Югары мәхкәмәсе кушуы буенча, Фәтхи Бурнашның әсәрләренә кабат экспертиза ясала. Гаепләрлек берничә дәлилләр булмаса да, Югары мәхкәмәнең җинаять эшләре буенча махсус коллегиясе 1941 елның 24 гыйнварында, ягъни әдипнең кулга алынуына нәкъ биш ай тулган көндә, аны ун елга ирегеннән, шуннан соң өч елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән хөкем карарын чыгара. Тоткынның кассация сорап язган гаризасы РСФСР Югары мәхкәмәсе тарафыннан кире кагылгач, аны этап белән Куйбышев (хәзерге Самара) өлкәсендәге «Безымянный» лагерена озаталар. Монда инде әдип гомеренең икенче һәм соңгы фаҗигале акты уйнала: төрмә ялчылары махсус оештырган әләк нигезендә Фәтхи Бурнаш өстеннән яңа җинаять эше кузгатылып, НКВДның Махсус киңәшмәсе 1942 елның 15 июль утырышында әдипне «сугыш шартларында Советка каршы коткы сүзләр тараткан өчен атарга» дигән рәхимсез һәм гаделсез хөкем карарын игълан итә. Карар шул ук елның 1 августында гамәлгә ашырыла.

Репрессив органнар Фәтхи Бурнашның кайчан атып үтерелүе турындагы фактны да туганнарыннан озак еллар буе яшереп тоталар, энесе Вафа, улы Рөстәм Бурнашевларның 1956 елгы реабилитация вакытында сорап язган гаризаларына: «Хезмәт белән төзәтү лагеренда җәза мөддәтен үткәндә, Фәтхи Бурнаш 1942 елда икенче тапкыр ун елга ирегеннән мәхрүм ителде һәм 1946 елның 1 августында төрмәдә үпкә эмфиземасыннан үлде», – дигән ялган җавап бирәләр. Бары 1988 елда гына, әдипнең тууына 90 ел тулу уңаеннан, КГБ архивына керү мөмкинлеге туып, язучының язмышына бәйле төгәл фактлар ачыклана.

Фәтхи Бурнаш егерме биш елга якын әдәби эшчәнлеге дәвамында егерме ике сәхнә әсәре, утызлап поэма, йөз илледән артык лирик, публицистик, сатирик шигырьләр, биш йөзгә якын тәнкыйди һәм публицистик мәкалә, рецензия, берничә дистә хикәя һәм фельетоннар яза, рус теленнән һәм башка телләрдән гомуми күләме 120–130 басма табак чамасында (ике меңләп китап бите!) матур әдәбият әсәрләре тәрҗемә итә. Бу зур байлык киләчәктә әле яңадан кайтып, сәнгатьнең, әдәбиятның үз законнары нигезендә өйрәнүне көтә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең музей мәгълүмат системаларын тәэмин итү бүлеге мөдире **Бугрова** Наталья Александровнага, «Әтнә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Зәйнуллина** Альбина Фирдинат кызына, «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең ут куючы рәссамы **Иванов** Денис Владимировичка, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директорының укыту-тәрбия эше буенча урынбасары **Курочкина** Алия Миңнерәшит кызына, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мамадыш туган якны өйрәнү музее» муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Потапова** Светлана Илсур кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Үзәкләштерелгән клуб системасы – Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең методика бүлеге мөдире **Ризванова** Нурия Җәүдәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Елховнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 5 номерлы нефть һәм газ чыгару цехының нефть һәм газ чыгару операторы **Красильников** Василий Ивановичка, «МехСервис – НПО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 2 номерлы Төбәк үзәге Лениногорск участогының нефть чыгару объектлары җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча өлкән мастеры **Кунакбаев** Илнур Нәҗип улына, «Чишмәойл» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Кондырчанефть» акционерлык җәмгыяте техник директоры **Сөләйманов** Разил Минсәгыйть улына, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Әлмәтнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе 5 номерлы нефть һәм газ чыгару цехының нефть һәм газ чыгару операторы **Хәйбуллин** Валириан Интер улына, «МАКойл» акционерлык җәмгыяте нефть һәм газ чыгару цехының сусызландыру һәм тозсызландыру җайланмасы операторы **Хуҗәхмәтов** Фәнил Кәрим улына **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Навигатор» яшьләр, инновация һәм профилактика программалары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары **Галимова** Алла Юрьевнага, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Таҗиева** Наилә Камил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

БЕР УРЫНЫНА ИКЕ АТЛЫЙСЫ

Кирәксә-кирәкмәсә урамга чыкмаска! Аяк астында ялтырап яткан боз корбанына әверелмәс өчен, белгечләр шушы кагыйдәне истә тотарга куша. Урамга чыккан очракта да аяк астына карап йөрергә киңәш итә алар. Ник дигәндә, бүген Татарстанда имгәнүчеләр саны бермә-бер арткан. Башкаладагы 7 нче номерлы шәһәр хастаханәсенең травматология бүлекләре имгәнүчеләр белән шыплап тулган. Балаларга ярдәм күрсәтүче белгечләрнең эше дә икеләтә арткан.

Кыйммәткәрәк төшә

7 нче номерлы шәһәр хастаханәсе табиб-травматологы Булат Зыятдинов сүзләренә караганда, бу көннәрдә травматология бүлегенә көненә уртача 13–19 кеше мөрәҗәгать итә. Күпләрнең умрау һәм бот сөяге сынган. Алардан соң тернәкләнеп аякка басу өчен шактый вакыт таләп ителә. Бозда таеп егылып имгәнүчеләр дә шактый.

– Болар бар да бик җитди имгәнүләр санала. Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең барысына да тиз арада ярдәм күрсәтелә. Кайчак хәтта төнге сәгать бергә-икегә кадәр операция ясарга да туры килә. Табибларга эш бермә-бер артты, – ди белгеч.

Булат Зыятдинов сүзләренә караганда, көннәр суытканчы яуган бозлы яңгыр хәлне тагын да катлауландырган. Күпләр, бигрәк тә өлкән яшьтәгеләр шушы көнне кирәксә-кирәкмәсә урамга чыгуы аркасында харап булган.

– Бүген безнең бүлектә, сөт алырга гына чыккан идем бит, дип бозлы яңгырда урамга чыкканнарына үкенеп яткан әби-бабайлар шактый. Шуңа күрә кышкы чорда, бигрәк тә аяк аслары начар булганда, аларның балаларына, якыннарына да игътибарлырак булырга кирәк. Әби-бабайларга кирәк-яракны үзең китереп бирергә яки курьер аша тапшырырга да мөмкин бит. Бозга егылып имгәнгән өлкән кешене аякка бастыруга, ким дигәндә, өч ай вакыт таләп ителә. Протез куйган очракта ул ел буе да тернәкләнергә мөмкин, – дип кисәтә табиб.

Шугалак түгел

Соңгы бер атна эчендә Республика клиник балалар хастаханәсенең травматология бүлегенә китерелгән балалар саны да 20 процентка арткан. Бүлек мөдире Руслан Хәсәнов сүзләренә караганда, балалар арасында кул сыну, умыртка баганасына зыян килү очраклары күп. Оча, бот, тубык сөяген сындыручылар да шактый.

– Балалар еш кына йөзтүбән егыла яки арт санына барып төшә. Егылганда алар куллар белән тотынып калырга тырыша. Шуңа күрә балалар арасында кул сындыру очраклары да күп очрый. Соңгы ике атнада бездә шундый 23 очрак теркәлде. 7 баланың аягы сынган иде, – ди белгеч.

Балалар еш кына мәктәптән кайтканда имгәнә икән. Бу аңлашыла да, ничә сәгать буе дәрес тыңлап утырган баланың, урамга чыккач, бераз хәрәкәтләнеп, шукланып аласы килә. Аяк астындагы боз булып каткан күлләвек тә шугалак кебек тоела башлый. Күп кенә балалар әнә шундый бозлы урыннарда шуып уйнаганда имгәнә дә инде.

Чана урынына ярый

Кыш көне алынган тән җәрәхәтләре турында сөйләгәндә, табиблар елның-елында тюбинг, «ватрушка» дип йөртелгән җайланмаларда тау шумаска киңәш итә. Алар аркасында алынган тән җәрәхәтләре, хәтта үлем очраклары (!) турында да даими ишетеп торабыз. Әле кыш башланырга да өлгермәде, Татарстанда алты бала «ватрушка» аркасында имгәнергә өлгергән инде.

Руслан Хәсәнов сүзләренә караганда, әлеге куркыныч җайланма сәгатенә 50 чакрым тизлек белән хәрәкәт итә. Шуңа таудан «ватрушка» белән шуып төшкән баланың, берәр кая килеп бәрелгән очракта, имгәнәсе көн кебек ачык.

– «Ватрушка»да тау шуганда, баланың башы белән аягына аеруча зур куркыныч яный. Башың белән агачка, каты кар көртенә килеп бәрелүең дә бик тиз. Моның исә үлем-китем белән дә тәмамлануы ихтимал, – дип кисәтә.

Шуңа күрә белгечләр «ватрушка»да махсус җиһазландырылган, бөтен куркынычсызлык кагыйдәләре үтәлгән махсус урыннарда гына шуарга киңәш итә. Казанда исә бүген андый бер генә урын да юк. Башка елларны «Мега» сәүдә үзәге янында эшләп килгән махсус шуу урыны да быел ябык. «Шуңа күрә «ватрушка»ны баланы утыртып йөрү өчен чана итеп кенә кулланырга кирәк», – ди Руслан Хәсәнов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КЫШ КӨНЕ ИМГӘНҮ-ҖӘРӘХӘТЛӘНҮЛӘРДӘН САКЛАНУ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

✸Юлдан барганда егылсагыз, түбәдән төшкән кар астында калсагыз, артык хәрәкәтләр ясарга тырышмагыз. Сынган урынны селкетергә ярамый! Яныгыздагылардан «ашыгыч ярдәм» чакыруларын сорагыз. Балагыз урамнан кергәч, баш әйләнүдән зарланса, тәнендә шешкән, кара көйгән урыннар булса, аягына баса, кулына уенчык тота алмаса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

✸Кышкы аяк киеме таймый торган, яссы табанлы булырга тиеш. Хәзер аяк киемен таюдан саклый торган махсус җайланмалар да сатыла. Аяк киеме астына шуларны беркетсәгез хәерлерәк. Баланың кышкы аяк киеме исә җылы да, уңайлы да булсын. Бер үлчәмгә зуррак булса, үкчәсенең биеклеге 1 сантиметрдан артмаса, яхшы. Артык биек үкчәле аяк киеме баланың табанына зыян салса, кысып торганы исә аякны тиз туңдырачак.

✸Бөтен гәүдә белән егылуга караганда, утырган очракта җәрәхәт алу куркынычы азрак. Умырткалыкны имгәнүдән саклау өчен, аркага түгел, бер якка егылырга тырышыгыз.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты коллективы, әнисе

СОЛТАНОВА Гөлрәйхан Әгъләм кызы

вафат булу сәбәпле, сәнгать фәннәре докторы, институтның Сәнгать белеме үзәге мөдире Рауза Рифкать кызы Солтанованың һәм аның якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

ak-bars.ru

Үз кеше

Шимбәгә каршы төндә Олег Знарок белән араны өзгән «Ак барс» якшәмбе кичендә бозга яңа остазлар җитәкчелегендә чыкты. Зиннәтулла Билалетдинов баш тренер ярдәмчесе саналса да, аның барлыгы беренче очрашуда ук сизелде.

Узган җомга көнне «Ак барс» үз бозында «Локомотив»ны отты. Казан командасы, быелгы сезондагы иң яхшы матчларның берсен уйнап, тамашачының күңелен җылытты. Очрашудан соң баш тренер Олег Знарок тамашачыга рәхмәт укыды, уенчыларын мактады, аларның тагын да яхшырак уйныйсын әйтте. Остазның кәефе яхшы иде, журналистлар да аны борчып тормады. Әмма матч тәмамланып, бер сәгать узуга, хоккей дөньясын шаулаткан хәбәр пәйда булды: Знарок үз теләге белән вазыйфасыннан киткән, клуб җитәкчелеге исә каршы килмәгән.

Бер яктан караганда, Олег Знарокның китүе гаҗәп түгел. Казанда ул Гагарин Кубогын яуларлык команда төзи алмады. Заманында зур җиңүләргә ирешкән тәҗрибәле остазның «йолдыз»ларны бер йодрыкка тупларга көче җитмәде. Әйтерсең тренер юк, ә хоккейчылар үзләре ничек тели – шулай уйный. Кайбер матчлардан соң әнә шундый тәэсир калды. Уенчыларның үзара төркемнәргә бүлгәләнүе турындагы сүзләрне кире каксалар да, «Ак барс»ның бер матч артыннан икенчесен оттыруы утсыз төтеннең булмавына ишарәләде. Иң тәҗрибәле уенчыларның берсе Александр Бурмистровның командадан куылуы да «Ак барс»та тынычлык юклыгын раслады.

Знарокның ноябрь ахырында, ягъни команда Омск – Новосибирск – Астана сәфәреннән кайткач китәсен фаразлаучылар булды. Әмма аңа «Ак барс»та тагын бер атна эшләргә насыйп булган икән. Дөрес булса, бу көнне эшеннән китәсен ул үзе дә белмәгән. Һәрхәлдә, уенчыларга да сиздермәгән, журналистлар янында да аны-моны әйтмәде.

«Ак барс»та сезон барышында баш тренер алмаштыру соңгы тапкыр 2004 елда булган иде. Меңьеллык алдыннан, «йолдыз»лар тупланган командага остаз булып чемпионат башланып, бер ай узгач, Владимир Вуйтек урынына Зиннәтулла Билалетдинов килде. 18 елдан соң тарих өлешчә булса да кабатлана. Дөрес, Зиннәтулла Билалетдинов бу юлы баш тренер түгел, әлеге вазыйфага вакытлыча билгеләнгән Юрий Бабенконың ярдәмчесе санала. Ләкин без барысын да аңлыйбыз.

Билалетдиновның барлыгы «Динамо»га каршы узган очрашуда ук сизелде. Команда игътибарлы уйнарга тырышты. Җиңелеп барса да, «Ак барс» ахырга кадәр көрәште. Уенчылар әйтүенчә, алар җиңәселәренә тамчы да шикләнмәде. Командага бүген, беренче чиратта, тынычлык кирәк. Уенчыларны көздән бирле күзәткән Билалетдинов исә аларның кимчелекләрен яхшы чамалый. Шуңа күрә клуб җитәкчеләренең Зиннәтулла Хәйдәр улыннан ярдәм сораулары да гаҗәп түгел. Ул – үз кеше. Читтән чакырылган кешегә командадагы хәлләрне аңлау өчен вакыт күп кирәк булыр иде.

Матч ахырында Билалетдинов журналистлар янына үзе килде. Кәефе шәп иде, иркенләп үз фикерләрен җиткерде:

– Кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышачакмын. Барысын да аңлыйм, егетләр яшь, аларга ярдәм кирәк. Узган ел дәвамында «Ак барс»ның генераль менеджеры клубка киңәшче итеп чакырды. Соңгы вакытта эшсез утырырга күнеккән идем, дөресен әйткәндә, бу миңа бик ошый иде. Әмма яңа эшкә алынгач, анысы да күңелемә якын булды. Уенчылар һәм тренерлар белән аралашу рәхәтлек бирә. Киңәшләремне бирәм, әмма фикерләремне көчләп такмыйм. Бу эш миңа ошый. Ә команда белән кайчанга кадәр эшлисемне әйтә алмыйм. «Ак барс»тагы үзгәрешләргә килгәндә, кайбер әйберләрне төзәтеп-үзгәртеп җибәрергә кирәк. Әмма бу эшне кинәт кенә башкарырга ярамый. Юрганны үз ягыма тарту булмаячак. Баш тренер бар, ә минем эшем – аңа булышу.

9 алтын

Көрәш буенча Россия чемпионатында Татарстан егетләре 9 алтын медаль яулады. Үз категорияләрендә чемпион булып Алексей Абрамов (Лаеш), Илназ Димиев (Лаеш), Рафаэль Бильданов (Әлмәт), Динар Кәримуллин (Лаеш), Ранис Галимуллин (Лаеш), Илмир Төхвәтуллин (Казан), Эльдар Хәмитов (Чаллы), Радик Сәлахов (Лаеш), Ранис Гыйләҗетдинов (Чаллы) танылды. Теләчедән Алмаз Сәетов исә – өченче урында.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Өйгә эш

Чыршы күркәсе – 14 сум, Яңа ел куяны – 1 мең 200 сум... Интернетта акча эшләүнең яңа төре чәчәк ата. Әти-әниләр балалар бакчасына, мәктәпкә дигән кул эшләнмәләрен сатып кына ала хәзер. Берәүләр болай да чамалы вакытны әрәм-шәрәм итәргә теләмәсә, икенчеләр акча эшли. Ярыймы, ярамыймы? Фикерләр төрле.

Кичке якта «Ватсап»тагы әти-әниләр төркеменә килгән хәбәр бөтенебезне аякка бастырды. Тәрбиячебез бер-ике көн эчендә кул эшләнмәсе ясап килергә кушкан. Әле аның да ниндиен?! Буш шешә, йогырт савыты, кәгазь тартма ише каты көнкүреш калдыгыннан матурлык иҗат итәргә кирәк. Моны бала белән эшлисе! Әй, китте шуннан сүз: балага бу эш кирәкме, әти-әниләрне ник мәҗбүр итәләр... Бәхәс шактый дәвам иткән булыр иде әле, мәсьәләгә бер әни нокта куйды: «Интегеп тә утырмыйм. Әзер кул эшләнмәләре интернетта сатыла. Теләгәнен сайлап ал. Өйгә кадәр китереп тә бирәләр...»

dreamstime.com

Шүрәле дә сатыла

Интернетта, чыннан да, нинди генә кул эшләнмәләре юк. Бәяләре төрле. Төсле кәгазьдән гади генә бизәкләп ясалган 20 сантиметрлы чыршыны, мәсәлән, 350 сумга саталар. Токмачны буяп ясалган зәвыклы чыршы кыйммәтрәк – 700 сум. Көнбагыш һәм карабодайдан керпе – 400 сум. Агач таякчыклардан эшләнгән йорт – 900 сум. Йорт янәшәсендә күл, эскәмия, төрле кош-кортлар да ясап куярга мөмкин. Моның өчен өстәп түлисе, әлбәттә. Иң кыйммәтлесе – Габдулла Тукайның Шүрәлесе. Сәйләннән ясалган әкият героен 1 мең 700 сумга тәкъдим итәләр. Теләсәң, кул эшләнмәсе өчен әзер материаллар сатып алырга да мөмкин. Кипкән бакча чәчәкләренең 5 данәсе – 120 сум, бер чыршы күркәсе – 14 сум.

Диана Сәлахиева интернетта кул эшләнмәләре сату белән шөгыльләнә.

– Мин моны эшкә дә санамыйм, киресенчә, кул эшләнмәсе ясаудан рәхәтлек алам. Декрет ялында утырам. Баштарак туганнар ярдәм итүемне сорый иде. Әзер эшләрне интернетка куйгач, заказ бирә башладылар. Намус белән эшлим. Остаханәм дә бар. Эш өчен кирәкле барлык материалларны үзем әзерлим. Ни теләсәләр, шуны ясап бирәм, моның өчен кирәкле эшнең фотосын җибәрү дә җитә, – ди ул. – Бәяләр 400 сумнан башлана. Кул эшләнмәсе көнендә-сәгатендә кирәк булса, ике тапкыр кыйммәтрәк. Уку елы башланганнан бирле 15 мең сумга якын акча эшләдем.

Лилиана Игнатова биш елдан артык кул эшләнмәләре сату белән шөгыльләнә. Төп эше дә шул. Социаль челтәрләрнең берсендәге төркемендә 20 меңнән артык язылучысы бар аның. Кул эшләнмәләрен берне-икене түгел, берьюлы ун-унбишне ясый. Аларны ил буйлап сата. Җиренә җиткереп ясалган эшләрнең бәясе дә аерыла. Яңа елга катыргы һәм йоннан ясалган 15 сантиметрлы куян, мәсәлән, 1 мең 200 сум тора.

– Кул эшләнмәсе ясарга иҗади сәләт кирәк. Шуңа күрә бөтен кешенең хәленнән килә торган эш түгел бу. Баласына әзер кул эшләнмәсе сатып алучы әти-әниләрне гаепләмим. Миңа кат-кат мөрәҗәгать итүчеләр дә күп. Соңгы арада кул эшләнмәсе сораучылар артты. Әти-әниләр, эштән кайткач, тагын нидер ясап утырырга вакыт юклыктан зарлана, – дип сөйләде Лилиана Игнатова.

«Балаларны күрергә дә вакытым юк!»

Гөлназ Хәсәнова – өч бала әнисе. Ике кызы – мәктәпкә, төпчекләре балалар бакчасына йөри.

– Өч балага кул эшләнмәсе ясарга вакытым да, артык теләгем дә юк, – ди ул. – Кул эшләнмәләрен атна саен сорап торалар. Берсенә ясасаң, икенчеләре сорый башлый. Шуңа күрә бик сирәк, билге алырга кирәк булганда гына ясыйбыз. Эштән кайткач, көндәлек мәшәкатьләр дә җитәрлек. Ишле гаилә булгач, ашарга пешерү, кер юу, җыештыру, дәрес әзерләү дә бик күп вакыт таләп итә. Бакчада, мәктәптә кул эшләнмәләре күргәзмәләрен күргәч, оста куллы әти-әниләргә шаккатам. Мондый эшләрдә баланың катнашы булуы гына шик тудыра.

Лилия Мусина ике улына кул эшләнмәләре сатып алуын яшерми.

– Эшкә иртәнге сәгать сигездә чыгып китәм, кичке сигездә кайтам. Нинди кул эшләнмәсе ди ул! Балаларны күрергә дә вакытым юк. Без сатып кына алабыз. Балаларга дигәч, акча кызганыч түгел. Улларым да каршы килми. Алар үзләре дә иҗат итәргә риза, тик бала ясаган кул эшләнмәсе, артык гади булганлыктан, төркемдәге шкаф башында утырып кала, ә яхшы эшләр күргәзмәгә китә. Улларымның да, башкалар кебек, бәйгедә урыннар аласы килә. Шуңа күрә елга бер-ике тапкыр кул эшләнмәсе сатып алабыз да, җиңү – кесәдә, – ди Лилия.

Төп максат – уртак хезмәт

Казанның 126 нчы номерлы балалар бакчасының өлкән тәрбиячесе Гөлия Фатыйхова сүзләренә караганда, өйдә кул эшләнмәсе ясауның төп максаты – уртак хезмәт.

– Балалар бакчаларында гадәттә төрле тематик атналар үткәрелә. Әнә шуның кысасында әти-әниләргә балалар белән бергә өйдә кул эшләнмәләре ясарга тәкъдим итәбез. Мәҗбүри түгел, әлбәттә. Бу – әти-әниләр бераз булса да балалары белән бергә вакыт үткәрсен өчен эшләнә. Өстәвенә бала үзе эшләгән әйбергә игътибарлырак булырга өйрәнә. Әти-әниләрнең буш вакыты аз булуын аңлыйбыз. Гомумән, бүген балалар буш вакытта үз көннәрен үзләре кайгырта. Сәгатьләр буе телефонда утырырга да мөмкиннәр. Шуңа күрә кич бергәләп кул эшләнмәсе ясау файдага гына. Шаккатыргыч иҗат җимеше ясарга димәгән, гади итеп эшләргә дә мөмкин, – дигән фикердә тәрбияче.

Казанның 16 нчы татар-инглиз гимназиясенең башлангыч сыйныф укытучысы Ләйсән Рәфыйкова әйтүенчә, кул эшләнмәсе ясауга бәйле өй эшләре укыту планы нигезендә бирелә.

– Балалар мөмкин кадәр күбрәк иҗат итсен, шул исәптән кул эшләнмәләре ясасын иде. Бер яктан, бу кулның вак моторикасын яхшыртса, икенче яктан, эзлекле һәм дөрес фикер йөртә белү сәләте тагын да камилләшә. Бүген укучылар арасында әсәрнең эчтәлеген сөйләп бирә алмаучылар да очрый. Чөнки төрле гаджетлар безнең өчен үзләре уйлый, үзләре сөйли. Мөстәкыйль иҗат исә – хыялга бирелергә бер сәбәп. Әти-әниләр дә ярдәм итә ала. Уртак хезмәт якынайта. Әмма бала йокыдан торган җиргә «күктән төшкән» кул эшләнмәсенең файдасы шулкадәр генә. Кызганыч, бала кулы тимәгән эшләр дә җитәрлек, – ди мөгаллим.

...Әзер эшләрне сатып алырга теләүчеләр чыннан да күпме? Бу сорауга җавап эзләп, балалар бакчасына дип сок савытыннан ясаган коены интернетка сатарга куйдым. Буш савыт барыбер чүпкә очачак иде, шуңа күрә аның үзкыйммәте юк дип алыйк. Коены гуашь белән буядык, анысы да өйдә бар. Коеның бурасына дигән махсус җеп – 100 сум (әле аның яртысыннан артыгы калды), бизәү өчен ялтыравык тасма һәм агачтан ясалган ике кош – 150 сум. Кул эшләнмәсе якынча 250 сумга төште, аны ясарга өч сәгать вакыт китте. Коены интернетка 500 сумга куйдым. Алучысы шул ук көнне табылды...

Эльвира ВӘЛИЕВА

Белгеч сүзе

Альбина ГӘРӘЕВА, балалар психологы:
– Кич өйдә бергәләп кул эшләнмәсе ясау – бала белән аралашу, аны ниләр борчый-кызыксындыра икәнен белү өчен менә дигән мөмкинлек. Үзегез күрерсез, эш арасында бала ачылып китеп сөйләшә башлаячак. Өстәвенә кул эшләнмәләре баланың киң фикер йөртү сәләтен яхшырта, сенсомоторика, ягъни хисләр һәм хәрәкәт белән идарә итүгә уңай тәэсир итә. Килешәм, бөтен бала да «бишле»лек иҗат итә алмый. Һәркайсыбызның көчле һәм кимчелекле яклары бар. Берәүләр шигырьне бер укып чыгуда истә калдырса, икенчеләр математиканы су урынына эчә.

КҮҢЕЛЕҢ АВЫРУ БУЛМАСЫН!

Инвалидлар ункөнлеге

Алсуның бер аягы икенчесеннән кыскарак. Тумыштан шулай. Кайчак йөргәндә уңайсызлык сизсә дә, Алсу үзе сер бирми. Бүген ул – иренең яраткан хатыны, өч баласының кадерле әнисе. Шуңа да аның күңелсезләнеп утырырга вакыты юк. Ул инде күптән бәхетен кадерләп, атлап йөри алганына сөенеп, һәр туган көнгә шатланып, гаиләсенә шөкер итеп яши. Хәлләрен белергә шалтыраткач та, бик ягымлы итеп җавап бирде.

– Элек мин өйдән дә чыкмый идем, – дип башлады ул сүзен. – 2014 елда республика күләмендә физик мөмкинлеге чикләнгән хатын-кызлар өчен бәйге уздырылганын белдем. Бик тә шунда катнашасым килде. Язмыштыр инде, шул бәйге минем тормышымны үзгәртте. «Татарстан энҗесе»ндә катнашучыларны Венера Иванова телевидение тапшыруына чакырды. Булачак ирем, мине шуннан күреп, ике көннән соң социаль челтәрләрдәге сәхифәмә язды, танышырга теләвен әйтте. Башта смс аша хәбәрләштек. Аннары телефоннан сөйләшә башладык. Бераздан күрештек. 3 ай узгач, без никах укыттык.

Балтач районының Түнтәр авылы кызы Сабадагы Сүләгә килен булып төшә. Иренең әти-әнисе аны бик яратып каршы ала. Алар әле дә бергә яшиләр. Алсу каенанасы һәм каенатасына рәхмәт укый.

– Әти белән әни бик ярдәм итәләр. Балаларыбызны карашалар. Без ирем белән кая барасы килә – шунда чыгып китәбез. Алар сүз әйтми, каршы килми. Безне аңлаганнарына да күңелем була. Күпләр каенана белән торудан курка. Балалар үстергәндә, әти-әнинең ярдәме әйтеп бетергесез бит, – ди Алсу.

Ире Азат белән өч бала үстерәләр. Уллары Ризванга – 7, кызлары Ләйсәнгә 2 яшь тулып киткән. Кечкенә Раянга өч кенә ай әле. Берсеннән-берсе кечкенә өч сабые булса да, Алсу кул эшләре белән шөгыльләнергә дә вакыт таба. Бәйли дә, чигә дә, тегә дә. Соңгы арада илһамы килми икән әле. Тик ул ясаган сабыннарны да, бәйләгән киемнәрне дә, чәчкә куя торган каптыргычларны да сораучылар күп. Кечкенә улы бераз үсеп китүгә, ул яңадан кул эшенә тотынмакчы. Әлегә аларның төп эше – сабыйларны тәрбияләү. Ризван белән Ләйсән икесе дә бакчага йөри икән. Азат исә күрше авыл мәчетендә имам вазыйфасын алып бара. Хатыны әйтүенчә, аның да эше күп. Алар икесе дә дин кушканча яши. Шуңа да күп очракта бер-берсенә юл куя беләләр. Алсу: «Гел яратышып кына яшәмибез, тормыш булгач, савыт-саба да шалтырый», – ди. Кайчакта үпкәләшүләрен дә яшерми.

– Мин озак итеп ачу саклап йөри алмыйм. Тиз онытам, – ди ул. – Тормышта бер-береңә терәк булырга кирәк. Кайчак дәшми калу да бик ярап куя. Тик мин иремнән зарлана алмыйм. Ул мине бик бәхетле итте. Бүгенге тормышыма сөенеп яшим. Үземне бик тә бәхетле хатын-кыз дип саныйм. Күңелдә бер генә теләк: минем кебек һәр хатын-кыз, тормышта тиң ярын табып, мин кичергән матур хисләрне кичереп, ана булу бәхетен татысын иде. Чирне бит сорап алмыйсың. Бүген йөгереп йөргән кеше икенче көнгә гарипләнергә дә мөмкин. Шуңа күрә кешегә кимсетеп карамаска кирәк. Тагын шунысы да бар: кайбер сау-сәламәт кешеләрнең күңелләре гарип була. Монысы инде бик куркыныч.

Кияүгә чыккач, Алсуга сынаулар аша узарга туры килә. Алар гаиләләре белән юл һәлакәтенә очрый. Үзенең ике аягы сына, улына да зыян килә. Әлеге вакыйгадан соң ул тормышның кадерен тагын да ныграк аңлый.

– Хәзер мин һәр көнгә рәхмәт әйтәм. Тормыштан зарланырга хакым юк. Аякларым йөреп тора, күзләрем күрә, колакларым ишетә. Шуңа мин бер дә күңелемне төшермим. Миннән дә начар хәлдә калган кешеләрне уйлыйм. Шул чакта оят та булып китә, – ди Алсу. – Иң мөһиме – үзеңнән оялмаска кирәк. Шул вакытта башкалар

да сине үзе белән тиң күрәчәк. Беркайчан да, мин булдыра алмыйм, дип үз дәрәҗәгезне төшермәгез. Физик мөмкинлеге чикләнгән кызлар үзләренең дә башкалар кебек икәнен, берәүдән дә ким түгеллекләрен белеп торсын. Бу дөньяда һәркем бәхеткә лаек. Бәхетле булу үзебездән тора. Шуны онытмыйк!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 380

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+